ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына кертелгән гражданнар, шулай ук махсуслаштырылган оешма белән үзара шартнамә нигезендә эшләүче юридик затлар белән хезмәт шартнамәләре төзүче гражданнар;»;

2) $6^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$6^1$ статья. **Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен торак төзелеше өчен бирү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре әлеге Закон кысаларында гамәлгә ашырыла торган социаль ипотекада катнашучы, даими яшәү урыны буенча авыл җирлекләрендә теркәлгән яшь белгечләр, бюджет өлкәсе һәм авыл хуҗалыгы тармагы хезмәткәрләре арасыннан булган гражданнарның милкенә, алар үз эшчәнлеген әлеге Законның 9 статьясында каралган төп юнәлешләр нигезендә башкаручы махсуслаштырылган оешма белән инвестицияләр каралган шартнамәләр төзегән очракта, индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бер мәртәбә түләүсез бирелергә мөмкин.
2. Әлеге Законның 5 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән категориядәге гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү максатларында дәүләт милкендәге

яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$ статьясы нигезендә махсуслаштырылган оешмаларга – республиканың коммерциягә карамаган оешмаларына түләүсез файдалануга бирелергә мөмкин.

3. Әлеге Закон кысаларында социаль ипотекада катнашучы гражданнарга дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.»;

3) 9 статьяда:

а) 9 пунктта «милекчелек» сүзен төшереп калдырырга;

б) 11 пунктта «белешмәләре нигезендә,» сүзләреннән соң «махсуслаштырылган оешманың» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар гамәлгә ашыра торган исәпкә алу белешмәләренә таянып, махсуслаштырылган оешманың инвестиция программасы нигезендә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә мохтаҗ гражданнарның җыелма реестрын төзиләр һәм алып баралар;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 31-ТРЗ